**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 июнь № 421

г. Казань

Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләүне, бастырып чыгаруны һәм таратуны гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 28 апрель, 346 нчы карары үз көчен югалтуын танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 21 июнь, 421 нче
карары белән расланды

**Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә электрон һәм басма рәвештә социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидияләр Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – акча белән баш эш итүче) тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә электрон һәм басма рәвештә социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплауга, нәшрият эшчәнлегенә булышлык күрсәтүгә күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәге таләпләргә җавап бирә торган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бирелә:

оешма Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән юридик зат булса;

оешма Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату буенча үз эшчәнлеген теркәлгән көннән кимендә ике ел дәвамында гамәлгә ашырса;

оешма штатында кимендә ике ел дәвамында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату буенча эш тәҗрибәсе булган белгечләр булса;

соңгы ике ел эчендә басмага әзерләнгән, бастырып чыгарылган һәм таратылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге китаплар тиражы кимендә 300 мең нөсхә тәшкил итсә;

алдагы ике ел эчендә басмага әзерләнгән, бастырып чыгарылган һәм таратылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге китапларның саны кимендә 150 исемдә булса;

алдагы ике ел эчендә басмага әзерләнгән, бастырып чыгарылган һәм таратылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге китапларның күләме кимендә 2 000 басма бит булса.

4. Субсидияләр түбәндәге чыгымнарны каплау өчен бирелә:

штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләргә эш хакы түләү;

бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәре түләү;

житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри медицина иминияте буенча кертемнәр түләү;

тотыла торган материаллар сатып алу;

авторлык һәм эргәдәш хокуклар буенча, архив материалларыннан, компьютер графикасыннан файдаланган өчен түләүләр;

элемтә хезмәтләре күрсәткән өчен түләү;

типографияләр хезмәтләре күрсәткән өчен түләү.

5. Субсидия алу өчен социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләүгә, бастырып чыгаруга һәм таратуга бәйле оешмалар акча белән баш эш итүчегә түбәндәге документларны кертә:

акча белән баш эш итүче раслаган форма буенча исәпләр һәм нигезле чыгымнар теркәлгән субсидия бирү турында гариза;

гамәлгә кую документларының, шулай ук аңа кертелгән барлык үзгәрешләрнең төп нөсхәсен һәм күчермәләрен (күзәтү өчен төп нөсхә);

оешманың штат расписаниесен;

агымдагы елда оешма тарафыннан социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чаралары планын;

бу Тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүне раслый торган документлар;

узган финанс елы өчен бухгалтерлык балансын;

барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча кичектерелгән бурычлар булмауны раслый торган документлар.

Документлар кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмасында бирелә ала.

Оешма үз башлангычы белән Вәкаләтле органга оешманы салым органында исәпкә кую турындагы таныклыкның күчермәсен бирергә хокуклы.

Күрсәтелгән документның күчермәсе оешманың үз башлангычы белән тапшырылмаган очракта Вәкаләтле орган аны федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органында ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә сората.

6. Акча белән баш эш итүче субсидия бирү турында гаризаны һәм аңарга теркәлгән документларны 30 календарь көне эчендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

оешманың әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты тапшырылмау.

8. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта акча белән баш эш итүче тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә оешмага субсидия бирүдән баш тарту турында хәбәр җибәрә.

9. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта акча белән баш эш итүче тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә оешмага карар күчермәсен һәм субсидия бирү турында шартнамә проектын

җибәрә. Акча белән баш эш итүче оешма тарафыннан имзаланган шартнамәне алганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә шартнамәгә кул куя.

Әгәр акча белән баш эш итүче субсидия бирү турында шартнамә проектын җибәргәннән соң 20 календарь көне эчендә оешма имзалаган шартнамә акча белән баш эш итүчегә тапшырылмаса, әлеге оешмага субсидия бирү турында карар гамәлдән чыгарылырга тиеш.

10. Субсидия бирү турында шартнамәдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны файдалану турында хисап тоту тәртибе һәм вакытлары, субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен оешма тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, оешманың (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерцияле оешмалардан тыш) акча белән баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очраклардан тыш алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю күздә тотыла.

11. Оешма ай саен (айның соңгы эш көненнән соңга калмыйча) акча белән баш эш итүчегә акча белән баш эш итүче раслаган форма буенча оешманың субсидия исәбеннән кайтарыла торган чыгымнары турында хисап тапшыра.

12. Акча белән баш эш итүче оешма айлык хисапны биргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә оешманың кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына субсидияне күчерә.

13. Субсидия алучы булган оешма субсидияләр керү һәм аларны тоту буенча аерым бухгалтер исәбе алып барырга тиеш.

14. Түбәндәге фактлар ачыкланган очракта, бирелгән субсидияләр акча белән баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 5 һәм 13 пунктлары шартларын бозганда;

субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм/яки документлар тапшырганда;

субсидиядән файдалану турында хисапларны билгеләнгән вакытта тапшырмаганда;

субсидияләрдән максатка яраксыз файдаланганда.

15. Субсидия бирү турында шартнамәдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше оешма тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

16. Субсидия кайтаруның әлеге Тәртипнең 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән вакытлары бозылган очракта акча белән баш эш итүче субсидияне кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә алу чараларын күрә.

17. Акча белән баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнарда билгеләнгән тәртиптә оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыралар.

18. Субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә акча белән баш эш итүче гамәлгә ашыра.